ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
Кошки авыл җирлеге Советы

Адресы: 422888, ТР, Әлки районы,
Кошки авылы, Дружбы урамы,9 а йорт
Тел/Факс 8 (84346) 73250

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Кошкинскогосельского поселенияАлькеевскогомуниципального района

422892, РТ, Алькеевский район,
с.Кошки, ул.Дружбы , д.9а
Тел/Факс 8 (84346) 73250

КАРАР

2019 нчы елның 11 нче ноябре 18№

Татарстан РеспубликасыӘлкимуниципаль
районы «Кошки авыл җирлеге» муни-
ципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә,Әлки районы Прокуратурасының хокук чыгару инициативасын Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85,86 статьясы нигезендә өйрәнеп,Кошкиавыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы « Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.(1 нче Кушымта)

2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

3. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарын, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының « Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының яңа редакциясендә, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Яңа Үргәагар авыл җирлеге территориясендә махсус җиһазландырылган стендларда игълан итәргә:Татарстан Республикасы, Әлки районы,Кошки авылы, Дружба урамы, 9а нчы йорт административ бинасында, Кошки авылы, М.Җәлил урамы, 21 нче йорт,авыл мәдәният йорты бинасындаһәм Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы « Кошки
авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы Гайфуллин М.Т.

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
«Кошки авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге
18 номерлы карарына 1 нче Кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Кошки авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

6 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү.»;

5 статьяның 1 пунктындагы 14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

22 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) торак пунктта торак пункт составына керүчеҗирлек чикләрен үзгәртү, әлеге торак пункт территориясен башка җирлек территориясенә җәлеп итү мәсьәләсе буенча;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

3) сайлау хокукына ия булган җирлектә яшәүчеләр саны 100 дән артык кеше булып, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре җирлекнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләр срогы турында мәсьәлә буенча гражданнар җыенын гамәлгә ашыручы җирлектә;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрегражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены белән гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

5) җирлек,шәһәр эче районы, федераль әһәмияттәге шәһәр эчендәге территориясе, муниципаль округы, шәһәр округы составына керүче, я муниципаль район чикләрендә урнашкан авылара территориядә,әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча торак пунктта;

6)яңа оешкан җирлек булдыру турында халык инициативасын алга җибәрү максатларында, шулай уксайлау хокукына ия булган кешеләр саны 300 дән артмаган яңа оешкан җирлектә дәяңа оешкан җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча авылара территориядә урнашкан торак пунктта;

7) авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән артмаган, авыл халкының түбән тыгызлыгы булган яки авыр үтемле җирлектә урнашкан җирлекне бетерү турындагы мәсьәлә буенча җирлектә;

8) авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча авыл торак пунктында.»;

22 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 1.1 нче пункт өстәргә:

«1.1.Авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс

үткәргәндә конкурс комиссияce составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин.»;

22 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 9 нчы пункт өстәргә:

«9. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы катнашуга хокуклы.Әгәр торак пунктта сайлау хокукына ия булган торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта булу мөмкинлеге булмаса,гражданнар җыены этаплап гражданнар җыенын тәртиптә үткәрү турындаТатарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Кошки авыл җирлегендә гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта үткәрелә.Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.Җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш биргән булса, Гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала.»;

28 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.Җирлек Советы депутаты 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә тиеш.Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, акчалата һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга тыю турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә чикләүләр, тыюлар, вазыйфалар үтәлмәгән очракта,әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса вакытыннан алда туктатыла.";

28 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 7 нче пункт өстәргә:

«7. 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә тиеш.Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, акчалата һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга тыю турында»гы Федераль законга билгеләнгән әлеге статьяның 7.2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә чикләүләрне, тыюларны бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда.Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә депутатка карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка бүтән җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.»;

28 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 8 нче пункт өстәргә:

"8.Үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре һәм хатынының(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре , чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән җирлек Советы депутатына карата, әгәр дә бу мәгълүмат әһәмиятле булып саналмый икән, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1)кисәтү;

2)җирлек Советы депутатын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында үз вәкаләтләре вакыты туктатылганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнен сайланулы органында вазыйфа биләүдән азат итү;

3) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итү белән даими нигездә вәкаләтләрдән азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләрне үтәүне тыю.»;

28 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 9 нчы пункт өстәргә:

«9.Җирлек Советы депутатына әлеге статьяның 7.3-1 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибе Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;

31 статьяның 22 нче пунктын төшереп калдырырга;

47 статьяның 1 пунктындагы 4 пунктчасының 3 нче абзацында "торак урыннар" сүзләрен "күпфатирлы йортта урыннар" сүзләренә алмаштырырга";

47 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасының 12 нче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

84 статьяның 1 нче пунктын "Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм башка норматив законнар" сүзләрен "нигезләмәләр" сүзенә алмаштырырга. "Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләрне һәм йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар,шулай ук бюджеттан акча бирү турында дәүләт (муниципаль) контрактлары, килешүләр (килешүләр) шартларын үтәү" сүзләрен өстәргә;

84 статьяның 2 нче пунктында "бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә" сүзләрен төшереп калдырырга.